КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 март г.Казань № 197

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1036 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче; 2016 ел, 27 июль, 517 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 805 нче; 2018 ел, 4 июль, 552 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1052 нче; 2018 ел, 18 декабрь, 1160 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына министрның дүрт урынбасарына, шул исәптән бер беренче урынбасарына ия булуны рөхсәт итәргә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аппараты хезмәткәрләренең иң чик санын түбәндәгечә билгеләргә:

аппарат буенча – вазыйфаи окладлар буенча 3 155,1 мең сумлык айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 218 берәмлек күләмендә, шул исәптән вазыйфаи окладлар буенча 1 914,6 мең сумлык айлык хезмәт өчен түләү фонды белән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аппараты эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрне 88 берәмлек күләмендә;

территориаль органнар буенча Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Зеленодольск, Әлмәт, Түбән Кама, Алабуга, Бөгелмә, Чистай, Лениногорск, Менделеевск муниципаль районнарындагы территориаль органнар буенча – вазыйфаи окладлар буенча 876,1 мең сумлык айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 79,5 берәмлек күләмендә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2004 ел, 30 декабрь, 614 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 21 март, 197 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасы**

- Министр
  - Министрның беренче урынбасары
    - Һәлакаттән коткару формированиеләрен төзү, аттестацияләү һәм теркәү бүлеге
    - Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге
    - Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге
  - Министр урынбасары
    - Табигый һәм техноген куркынычсызлык бүлеге
    - Территориаль үзара хезмәттәшлек итү һәм тернәкләндерү бүлеге
    - Перспектив үсеш бүлеге
    - Гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге
  - Министр урынбасары
    - Вазыйфаи затларны һәм халыкны әзерләү бүлеге
    - Көндәлек һәм оператив идарә секторы
    - Шәһәр идарә итү пункты
    - Шәһәр читендәге идарә итү пункты
  - Министр урынбасары
    - Геомәгълүмат системалары бүлеге
    - Мәгълүмат коммуникацияләре технологияләре һәм мәгълүматны саклау
    - Хәбәр итү һәм элемтә бүлеге
    - Гадәттән тыш хәлләр мониторингы һәм аларны фаразлау секторы
  - Эшләр идарәчесе
    - Эшчәнлекне планлаштыру бүлеге
    - Мәгълүмат бүлеге
    - Административ-хуҗалык бүлеге
  - Финанс–икътисад идарәсе
  - Хокукый тәэмин итү бүлеге
  - Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге
  - Мобилизация эше секторы
  - Серлелек режимы һәм махсус элемтә теркеме
  - Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча идарәләре

_______________